| | |
|---|---|
| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |

ПРИКАЗ БОЕРЫК

08.06.2020 Казан шәһәре № 56

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 17 сентябрендәге 84 номерлы боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең норматив хокукый актын федераль законнарга яраштыру максатларында

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 17 сентябрендәге 84 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 7 июнендәге 68 номерлы, 2019 елның 4 октябрендәге 109 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре) белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең хокук идарәсе юридик бүлегенә бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең җыелма анализ бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2020 елның 08.06.2020 № 56
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 17 сентябрендәге 84 номерлы боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.5 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.3.5. Инспекциянең урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Инспекциянең электрон почта адресы турында мәгълүмат Инспекциянең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендларында, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урында һәм Инспекциянең рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Инспекциянең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы яки шәһәр округы шәһәр (авыл) җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Төзүче оешмалар тарафыннан җитешсезлек очраклары бетерелгәннән соң, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланылган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителү таләпләренә җавап бирү турында ярашлылык бәяләмәсе бирү. | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 1 февралендәге 54 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 16 пункты |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе | «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 622 номерлы карары) |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Төзүче оешмалар тарафыннан җитешсезлек очраклары бетерелгәннән соң, төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь | Нигезләмәнең 19 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | төзелеш объектының проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланылган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителү таләпләренә җавап бирү турында ярашлылык бәяләмәсе (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә) бирү (1 нче кушымта);<br>ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар (2 нче кушымта) | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Ярашлылык турында бәяләмә бирү турында гариза теркәлгән көннән башлап ун эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтү чорын туктатып тору каралмаган<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче (аның вәкиле) мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта яки электрон адреска) җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла | Нигезләмәнең 19 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен | 1. Ярашлылык турында бәяләмә бирү турында гариза (3 нче кушымта).<br>2. Шәхесне таныклый торган документ.<br>3. Мөрәҗәгать итүче зат исеменнән персональ белешмәләрне эшкәртүгә рөхсәт бирү вәкаләтен дә күрсәтеп, вәкилнең (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән | Нигезләмәнең 19 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | вәкил эш йөртсә) вәкаләтләрен раслаучы документ.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:<br>- шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>- почта юлламасы белән.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның | Бу категориягә кертелергә мөмкин булган документларны тапшыру таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булмавы;<br>капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, кулланылган төзелеш материалларына, башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына экспертизаларның, тикшерүләрнең, лаборатор һәм башка сынауларның булмавы | Нигезләмәнең 19 пункты;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2013 елның 4 декабрендәге 94 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты;<br>«Татарстан Республикасы |

| | | |
|---|---|---|
| | | дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2011 елның 13 августындагы 675 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 675 номерлы карары) |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалардан | Дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып түбәндәгеләр тора:<br>капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, кулланылган төзелеш материалларына, башкарылган эшләргә һәм кулланылучы төзелеш материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатор | 675 номерлы ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | һәм башка сынаулар | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Төзелешне гамәлгә ашыручы зат башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына экспертизалар, тикшеренүләр, лаборатор һәм башка сынаулар үткәрүгә чыгымнарны каплый.<br>Күрсәтелгән акчалар бюджет керемнәре администраторының Татарстан Республикасы буенча федераль казначылык идарәсенә күчерелә.<br>Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь ремонтлаганда башкарылган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына экспертиза, тикшеренүләр, лаборатор һәм башка сынауларны үткәрү чыгымнарын каплау өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең «Татарстан Республикасы территориясендә капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь төзекләндергәндә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына экспертизалар, тикшерүләр, лаборатор һәм башка сынаулар үткәргәндә кулланыла торган төзелеш материалларына һәм кулланылучы төзелеш материалларына экспертиза, тикшеренүләр, лаборатор һәм башка сынаулар үткәрү чыгымнарын исәпләү тәртибен һәм коэффициентларын раслау турында» 2009 елның 18 декабрендәге 9-9/нпс номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 18.12.2009 № 9-9/нпс карары) белән | 675 номерлы ТР МК карары;<br>Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитеты идарәсенең 18.12.2009 №9-9/нпс карары;<br>ТР Министрлар Кабинетының 622 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе турындагы нигезләмәнең 4.1 пунктындагы 4.1.5 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | расланган. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Гариза тапшырылган көнне. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган | Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр белән җиһазландырылган бинада һәм бүлмәләрдә күрсәтелә:<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>янгынга каршы система;<br>документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы визуаль һәм текстлы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы булган урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү):<br>Казан шәһәре, Б. Красная урамы, 15/9 йорт адресы буенча урнашкан бинага инвалидларның үтеп керүен тәэмин итү максатларында бина фасадының керә торган урынында сул яктан инвалидлар өчен персоналны чакыртып алу төймәсе урнаштырылган.<br>Әлеге чакырту төймәсенә сигнал биргәндә инспекция персоналы аларны бинага күчерә | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>2) мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>3) дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы»нда тулы мәгълүмат булу;<br>4) мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен бинага дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыкларсыз үтеп | |

| | | |
|---|---|---|
| технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалана алу (шул исәптән тулы күләмендә) яки файдалана алмау мөмкинлеге | керүен тәэмин итү (бинага һәм аның чикләрендәге бүлмә урыннарына җайлы керү-чыгу);<br>5) инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;<br>3) документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә тапшырганда чиратлар булмау;<br>4) дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булмау.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазифаи зат белән гариза бирүче арасында бер мәртәбә хезмәттәшлек итү күздә тотыла.<br>Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтү гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Инспекциянең (http://gsn.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация Инспекциянең рәсми сайтындагы интернет-кабул итү системасы аша электрон рәвештә алынырга мөмкин.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон. |

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Инспекция, Инспекциянең вазыйфаи заты, дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Инспекциягә шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә Инспекция башлыгы карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

(Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар формаларын раслау турында» 2020 елның 12 мартындагы 107 номерлы боерыгы белән расланган)

20___ елның «___»_______
№ _______боерык белән
РАСЛАНДЫ

Эш номеры: _______________ Нөсхә: ____________

**Төзелгән (үзгәртеп корылган) капиталь төзелеш объектының проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланылган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителү таләпләренә җавап бирүе турында**
**БӘЯЛӘМӘ**

________________________________ « ___» _________ 20__ ел
(төзү урыны)

Әлеге БӘЯЛӘМӘ бирелде

_________________________________________________
(төзүче оешманың, техник заказчының атамасы,
_________________________________________________
ОГРН, ИНН, урнашу урыны – юридик затлар өчен;
_________________________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме[1], яшәү урыны адресы, ОГРНИП, ИНН – шәхси эшкуарлар өчен;
_________________________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме[1], паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны адресы – физик затлар өчен)

һәм шуны раслый: капиталь төзелеш объекты

_________________________________________________
(төзелеш өчен рөхсәт нигезендә капиталь төзелеш объектының исеме,
_________________________________________________
кыскача проект сыйфатламалары, төзү, үзгәртеп кору этабын тасвирлау,
_________________________________________________
төзелеш, үзгәртеп кору этабына рөхсәт бирелгән очракта;
_________________________________________________
капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре составына кертелгән күрсәткечләрнең норматив күрсәткечләре

урнашкан адресы:
_________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының почта яисә төзелә торган адресы)

Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт
_________________________________________________

___

(бирелгән номеры һәм датасы, аны биргән орган яки оешма, гамәлдә булу срогы)

Проект документациясенә уңай экспертиза бәяләмәсе

___

(бәяләмә номеры һәм аны бирү датасы, аны раслаган орган яки оешма[2]; проектның баш инженеры бәяләмәсе[3])

Проект документациясенә дәүләт экология экспертизасы буенча уңай бәяләмә, әгәр капиталь төзелеш объектының проект документациясе дәүләт экология экспертизасын узарга тиешле булса

___

(номеры һәм раслау датасы, аны раслаган башкарма хакимият органы)

төзүне, үзгәртеп коруны башлау ___

(эшләрне башлау датасы)

төзүне, үзгәртеп коруны тәмамлау ___

(эшләрне тәмамлау датасы)

Таләпләргә ТУРЫ КИЛӘ

___

(проект документлары бүлекләренең исемнәре һәм шифрлары)

Энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең норматив һәм фактагы[4] күрсәткечләре, аның нигезендә объектның энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм аның кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә туры килүе билгеләнә торган башка мәгълүмат[5]

___

Капиталь төзелеш объектының энергетика нәтиҗәлелеге классы[6]

___

Әлеге БӘЯЛӘМӘНЕ бирү нигезләре:

___

(төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү акты номеры, датасы)

| ___ | ___ | ___ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (тулы имза)[7] |

Бәяләмә нөсхәсе алынды:

___

(төзүче оешманың яисә техник заказчының вәкиле тарафыннан вәкиллек турында документ реквизитларын күрсәтеп тутырыла)

| ___ | ___ | ___ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (тулы имза) |

--------------------

[1] Булган очракта күрсәтелә.

[2] Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9, 3.10 өлешләре нигезендә эксперт ярдәме барышында бирелгән экспертиза бәяләмәләре дә күрсәтелә.

[3] Төзүче оешма яисә техник заказчы тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше

кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына кертелгән үзгәрешләр расланган очракта.

[4] Проект документларына үзгәрешләр керткәндә яки кирәкле техник документация булмаганда тикшеренүләр, үлчәүләр, экспертизалар, сынаулар үткәрелгән очракта.

[5] Энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре кагылмый торган капиталь төзелеш объектларыннан тыш.

[6] Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнар нигезендә билгеләнә торган энергетика нәтиҗәлелеге классын бирү мәҗбүри булган капиталь төзелеш объектларына карата күрсәтелә.

[7] Бәяләмә объект төзелеп беткән (үзгәртеп корылган) объектны тикшерүдә (тикшерүләрдә) катнашкан дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының вазыйфаи затлары тарафыннан имзалана.»;

2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Форма

(Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар формаларын раслау турында» 2020 елның 12 мартындагы 107 номерлы боерыгы белән расланган)

20___ елның «___»_______ №

________________боерык белән

РАСЛАНДЫ

Эш номеры: _______________ Нөсхә: ____________

**Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланылган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителү таләпләренә җавап бирү турында ярашлылык бәяләмәсе бирүдән баш тарту турында**

**КАРАР**

______________________________________ «___» ____________ 20__ ел.

(төзү урыны)

Әлеге КАРАР бирелде

______________________________________________________________

(төзүче оешманың, техник заказчының атамасы,

______________________________________________________________

ОГРН, ИНН, урнашу урыны – юридик затлар өчен;

______________________________________________________________

фамилиясе, исеме, атасының исеме[1], яшәү урыны адресы, ОГРНИП, ИНН – шәхси эшкуарлар өчен;

______________________________________________________________

фамилиясе, исеме, атасының исеме[1], паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны адресы – физик затлар өчен)

төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының

______________________________________________________________

(төзелеш өчен рөхсәт нигезендә капиталь төзелеш объектының исеме,

______________________________________________________________

кыскача проект сыйфатламалары, төзү, үзгәртеп кору этабын тасвирлау,

______________________________________________________________

төзелеш, үзгәртеп кору этабына рөхсәт бирелгән очракта;

урнашкан адресы:

______________________________________________________________

(капиталь төзелеш объектының почта яисә төзелә торган адресы)

капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителешенә карата таләпләргә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелегенә карата таләпләргә һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителешенә карата таләпләргә туры килүе турында БӘЯЛӘМӘ бирүдән баш тарту хакында.

Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт

______________________________________________________________

(бирелгән номеры һәм датасы, аны биргән орган яки оешма, гамәлдә булу срогы)

Проект документациясенә уңай экспертиза бәяләмәсе

______________________________________________________________

(бәяләмә номеры һәм аны бирү датасы, аны раслаган орган яки оешма[2]; проектның баш инженеры бәяләмәсе[3])

Проект документациясенә дәүләт экология экспертизасы буенча уңай бәяләмә, әгәр капиталь төзелеш объектының проект документациясе дәүләт экология экспертизасын узарга тиешле булса

______________________________________________________________

(номеры һәм раслау датасы, аны раслаган башкарма хакимият органы)

төзүне, үзгәртеп коруны башлау ________________________________

(эшләрне башлау датасы)

төзүне, үзгәртеп коруны тәмамлау ________________________________

(эшләрне тәмамлау датасы)

Әлеге КАРАР төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү нәтиҗәләре нигезендә кабул ителде

_______________________________________________________________

(төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү акты номеры, датасы)

анда билгеләнгәнчә:

_______________________________________________________________

(таләпләре бозылган проект документларының исеме һәм реквизитлары,

_______________________________________________________________

төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерүне тәгәлләү датасына бетерелмәгән)

| ________________________ | __________ | ____________________ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (тулы имза) |

Бәяләмә нөсхәсе алынды:

_______________________________________________________________

(төзүче оешманың яисә техник заказчының вәкиле тарафыннан вәкиллек турында документ реквизитларын күрсәтеп тутырыла)

| ________________________ | __________ | ____________________ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (тулы имза) |

--------------------

[1] Булган очракта күрсәтелә.

[2] Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9, 3.10 өлешләре нигезендә эксперт ярдәме барышында бирелгән экспертиза бәяләмәләре дә күрсәтелә.

[3] Төзүче оешма яисә техник заказчы тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына кертелгән үзгәрешләр расланган очракта.»;

5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

**БОЕРЫК** **КҮРСӘТМӘ**

_____________ Казан шәһәре № ____________

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында» 2006 елның 1 февралендәге 54 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карарына, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларның рәвешләрен раслау турында» 2020 елның 12 мартындагы 107 номерлы боерыгына, Инспекциянең _____________ № _________ боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына таянып һәм төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү турында __________ № ____ акт нигезендә,_______________ __________ адресы буенча урнашкан, төзелгән (үзгәртеп корылган) капиталь төзелеш объектының ______________________________ проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланылган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителү таләпләренә җавап бирүе турындагы бәяләмәне РАСЛЫЙМ.

Башлык урынбасары ________________________

**Искәрмә:** боерык Инспекция аппаратының контроль бүлеге башлыгы, Хокук идарәсе башлыгы, территориаль орган җитәкчесе тарафыннан килештерелә.»;

6 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

___________ Казан шәһәре № ____________

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында» 2006 елның 1 февралендәге 54 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карарына, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларның рәвешләрен раслау турында» 2020 елның 12 мартындагы 107 номерлы боерыгына, Инспекциянең _____________ № _________ боерыгы белән расланган Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергияне нәтиҗәле файдалану таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының файдаланылучы энергетика ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазланганлык таләпләренә туры килүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына таянып һәм төзелеп беткән капиталь төзелеш объектын тикшерү турында __________ № ____ акт нигезендә, аның нигезендә түбәндәге җитешсезлекләр ачыкланган:

________________________________________________________________

җитешсезлекләр

________________________________________________________________

Төзелгән, үзгәртеп корылган, _______________ адресы буенча урнашкан капиталь төзелеш объектының ___________________ ______________ проект документациясе таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелегенә таләпләренә һәм капиталь төзелеш объектының кулланылган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителү таләпләренә җавап бирүе турында ярашлылык бәяләмәсе бирүдән баш тарту турындагы карарны РАСЛЫЙМ.

Башлык урынбасары ______________________

**Искәрмә:** боерык Инспекция аппаратының контроль бүлеге башлыгы, Хокук идарәсе башлыгы, территориаль орган җитәкчесе тарафыннан килештерелә.».